СОВЕТ ВЕРХНЕТАКЕРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ ТӘКЕРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

## Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлеге составына кергән Югары Тәкермән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2019 ел, 17 ноябрь** **№ 7**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 17 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар түбәндәге мәсьәлә буенча җыен беркетмәсе төзелде: “2020 елда Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлегенең Югары Тәкермән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, биш һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүчеләрдән, балачак инвалидларыннан тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?”

- Югары Тәкермән авылында авария хәлендәге янгын резервуарын сүтү (алга таба төзекләндерү) (грунт белән каплау һәм бетонлау, эшләр өчен килешү буенча түләү).
- Югары Тәкермән торак пунктында эчке юлларга вак таш түшәү (эшләр өчен килешү буенча түләү).
- Югары Тәкермән торак пунктында юлга вак таш түшәү һәм бетонлау (эшләр өчен килешү буенча түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 330 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар җыенында катнашучылар саны 237 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:
“Әйе” позициясе өчен 237 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;
“Юк” позициясе өчен _0_ җыенда катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлегенең Югары Тәкермән торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – гамәлдә дип таныырга.

“2020 елда Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлегенең Югары Тәкермән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, биш һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүчеләрдән, балачак инвалидларыннан тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?” мәсьәләсе буенча карарны таныырга һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Югары Тәкермән авылында авария хәлендәге янгын резервуарын сүтү (алга таба төзекләндерү) (грунт белән каплау һәм бетонлау, эшләр өчен килешү буенча түләү).
- Югары Тәкермән торак пунктында эчке юлларга вак таш түшәү (эшләр өчен килешү буенча түләү).
- Югары Тәкермән торак пунктында юлга вак таш түшәү һәм бетонлау (эшләр өчен килешү буенча түләү).

2. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Югары Тәкермән авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, Минзәлә муниципаль районы сайтында: http://menzelinsk.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы һәм http://pravo.tatarstan Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Гамәлдәге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлегенә җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ________________ А.Ә.Шәрипова.
(имза) (тулысынча имза)

Югары Тәкермән авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе ________________ А.Ә.Шәрипова.
(имза) (тулысынча имза)